**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү күләмен арттыру максатында **карар бирәм:**

1. 2022 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-240 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 3 маендагы ПУ-347 номерлы һәм 2021 елның 13 декабрендәге ПУ-944 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар биләүче Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-243 номерлы Указы нигезендә билгеләнгән вазыйфаи окладлары күләмен арттырырга.

2. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын исәпләгәндә, әлеге Указның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте территориаль органы җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладлары күләмен 1,04 тапкыр индексацияләргә һәм ул 11 958 сум тәшкил итәчәк.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына каралган бюджет ассигнованияләре чикләрендә финанслауны башкарырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 19 август
№ ПУ-576